ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 42-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары О.М. Воронова, Р.С. Гайнетдинова, С.М. Захарова, Е.И. Кузьмичева, Л.Н. Маврина, А.Р. Нәбиева, А.Н. Надыршина тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 42-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 211-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
С.М. Захарова,
О.М. Воронова,
Р.С. Гайнетдинова,
Е.И. Кузмичева,
Л.Н. Маврина,
А.Р. Нәбиева,
А.Н. Надыршина
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» 2022 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 34 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), «педофилияне пропагандалый торган мәгълүматтан,» сүзләреннән соң «бала табудан баш тартуны пропагандалый торган мәгълүматтан,» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законын «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны яклау хакында» Федераль законның $10^6$ и $15^1$ статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 411-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында әзерләнде.

Дәүләт нигезләренең берсе булып гаилә тора, аның мөһим функциясе тулы кыйммәтле шәхесне һәм социаль дәвамлылыкны һәм төрле буыннар элемтәсен тәэмин итүче гражданны һәрьяклап үстерү һәм социаль яктан уңышлы булдыру өчен кирәкле мохит тудырудан гыйбарәт.

Традицион гаилә кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту максатларында югарыда күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына баланы бала табудан баш тартуны пропагандалый торган мәгълүматтан яклау турында нигезләмә өстәргә тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында»Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.